Родная (татарская) литература

**Йомгаклау контроль эше.**
**Үткәрү вакыты:    май, 2020 нче ел.**
**Үткәрү формасы:** тест биремнәрен башкару. Күләме 45 минутка исәпләнгән.
**Максат:** укучыларның ел буена алган белем – күнекмәләрен тикшерү.
**предмет нәтиҗәләре:** татар әдипләре исемнәрен һәм алар язган әсәрләрне белү; фольклор төшенчәсенә аңлатма бирә белү; татар әдәбиятына үз мөнәсәбәтен формалаштыра, бәяли белү; укыган  әсәр буенча сорауларга җавап бирә алу; әдәбиятның образлы дөньясын сүз сәнгате күренеше буларак аңлау.
**регулятив нәтиҗәләр:**
- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белергә;
- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белергә **өйрәнәчәкләр.**

**танып – белү нәтиҗәләре:**
- логик фикерли белергә;
- иҗади һәм эзләнү характерындагы  проблеманы  билгеләргә **өйрәнәчәкләр.**

Биремнәр  ел дәвамында үтелгән материалны үз эченә ала. Сораулар “**Борын-борын заманда”, “Әкият яздым, укыгыз...”,  “Хыял канатларында”, “Белем баскычлары”, “Балачак — хәтерләрдә мәңге калачак...”, “Кояшлы ил – бәхет иле”, “Ватаным өчен”, “Кеше – табигать баласы”** бүлекләреннән алынган.
**Биремнәр**
**1 нче вариант.**
**Планлаштырылган нәтиҗә:** татар әдипләре иҗатына һәм әдәбият теориясенә караган сорауларга дөрес җавап табу.
**База дәрәҗәсе – “Укучы өйрәнәчәк”  бүлеге буенча биремнәр:**
1. Фольклор — сүзе ... дигәнне аңлата.
А)хикәя, Ә) әкият  Б) халык авыз иҗаты
2. Габдулла Тукай язган әсәрне билгеләгез.
А) «Су анасы» Ә) «Патша белән карт» Б) «Гафият турында әкият»
3. Гаяз Исхакыйның «Мөгаллим» әсәре
А) укучылар һәм укытучы турында  Ә) балалар һәм әниләре турында  Б) байлык һәм сатучылар турында
4. Габдулла Тукай «Исемдә калганнар» әсәрендә  кем турында яза?
А) апасы турында  Ә) абыйсы турында  Б) үзе турында
5. Опера —
А) зур күләмле вокаль әсәрнең  шигъри юллар белән язылган тексты  Ә) музыкаль-драматик сәнгать   жанры. Аның әдәби нигезендә либретто ята  Б) әкият нигезендә, лиро-эпик әсәр (поэма) формасында язылган арадаш (смешанный) жанр төре
6.Әсәрләрне һәм авторны туры китерегез.
А)Муса Җәлил         А) «Сөйләр   сүзләр бик куп алар”
Ә) Гадел Кутуй        Ә) «Соңгы жыр”
Б)Фатих Кәрим       Б) «Рөстәм мажаралары”
7. «Бәләкәй Апуш» картинасы
А)«Исемдә калганнар» әсәре буенча ясалган  Ә)«Туган тел» шигыре буенча ясалган Б) Тукайның балачагын күреп  ясалган.
**Югары дәрәҗә - “Укучыга күнекмәләргә ия булу мөмкинлеге бирелә” бүлеге буенча биремнәр:**
***8.  Дәрдемәнд шигыреннән дөрес булган юлны табыгыз.***
А) Бүтән һөнәр белү — яхшы һөнәрдер;
Ә) Бүтән шигырь белү яхшы һөнәрдер;
Б) Бүтән телләр белү — яхшы һөнәрдер.
***9.  «Алтынчәч» либреттосында  кызны кем коткара?***
***1) Җик;***

***2) Урмай;***
***3) хан.***
6 нчы класс

**Контроль эш.**
**Үткәрү вакыты: май, 2020 нче ел.**
**Үткәрү формасы:** тест биремнәрен башкару. Күләме 45 минутка исәпләнгән.
**Максат:** укучыларның ел буена алган белем – күнекмәләрен тикшерү. Йомгаклау контроль эш материалы укучыларның белем дәрәҗәсенә карап төзелде. 1нче , 2 нче вариант биремнәре **база дәрәҗәсе – "Укучы өйрәнәчәк" бүлеге буенча биремнәр,** 3нче, 4 нче вариант- "**Укучыга күнекмәләргә ия булу" мөмкинлеге бирелә**
**Предмет нәтиҗәләре:** татар әдипләре исемнәрен һәм алар язган әсәрләрне белү; фольклор төшенчәсенә аңлатма бирә белү; татар әдәбиятына үз мөнәсәбәтен формалаштыра, бәяли белү; укыган әсәр буенча сорауларга җавап бирә алу; әдәбиятның образлы дөньясын сүз сәнгате күренеше буларак аңлау.
**регулятив нәтиҗәләр:**
- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белергә;
- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белергә **өйрәнәчәкләр.**

**танып – белү нәтиҗәләре:**
- логик фикерли белергә;
- иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләргә **өйрәнәчәкләр.**

Биремнәр ел дәвамында үтелгән материалны үз эченә ала. Сораулар "**Мифлар дөньясыннан — чынбарлыкка", "Халык моңнары: җырлата да, елата да... "Кадерле син, кеше-туганым!", "Энҗе карлар явып үткән...", "Акыл — тузмас кием, белем — кипмәс кое. "Ил өстендә илле дустың булсын.", "Көлке көлә килә...", "Һәр фасылың гүзәл, табигать!"** бүлекләреннән алынган.
**Чыганак:**
1) Дәреслек: «Татар әдәбияты», Рус телендә төп белем бирү оешмалары өчен дәреслек. 6 нчы с-ф. 2 кисәктә; төзүче–авторлары Ә.Р.Мотыйгуллина,Р.Г.Ханнанов, Л.Х.Хисмәтова. – Казан: «Мәгариф-Вакыт», 2017 ел.
2) Өстәмә әдәбият: Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында ( татар телен өйрәнүче укучылар белән) эшләүчеукытучылар өчен методик әсбап. 6 нчы с-ф. /Ә.Р. Мотыйгуллина, Р.Г. Ханнанов, Л.К. Хисмәтова, Л.М. Гыйззәтуллина. – Казан: "Мәгариф – Вакыт"нәшр., 2015.

**Биремнәр**
**1 нче вариант.**
**Планлаштырылган нәтиҗә: татар әдипләре иҗатына һәм әдәбият теориясенә караган сорауларга дөрес җавап табу.**
**База дәрәҗәсе – "Укучы өйрәнәчәк" бүлеге буенча биремнәр:**
1 нче вариант

1. Халык авыз иҗаты әсәрләренең авторы кем?

А) язучы
Ә)халык
В)шагыйрь
2. "Кем эшләми – шул ашамый" – бу нинди жанр?
А)мәкаль
Ә)әйтем
Б)такмак
3. Г.Тукайның "Туган авыл" җырына көй иҗат иткән композитор кем?
А)Рөстәм Яхин

Ә)Фәрит Яруллин
Б)Алмаз Монасыйпов
4.”Туган тел” җыры сүзләренең авторын билгеләгез:
А)Габдулла Тукай
Ә)халык
Б)Муса Җәлил
5.Татарстан Республикасы Дәүләт гимнының авторларын билгеләгез:
А)Рөстәм Яхин, рамазан Байтимеров
Ә)Салих Сәйдәшев, Габдулла Тукай
Б)халык
6.Гимн ул –
А)тантаналы җыр, дәүләт символы
Ә)тарихи җыр
Б)халык җыры
7.Ә.Еники “Туган туфрак” хикәясендә нинди авыл турында яза?
А)Корысаз
Ә)Каракош
Б)Коркачык
8.”Әбүгалисина” әсәрен кем язган?
А)Абдулла Алиш
Ә)Каюм Насыйри
Б)Фәнис Яруллин
9.Мокамайның чын исеме:
А)Мөхәммәтҗан
Ә)Мөхәммәтшакир
Б)Мөхәммәтһади
10.”Туган ягым – яшел бишек” әсәрен кем язган?
А)Роберт Әхмәтҗанов
Ә)Гомәр Бәширов
Б)Гәрәй Рәхим.

7 нче класс

**Контроль эш.**

**Үткәрү вакыты:** **май, 2020 нче ел. Үткәрү формасы:** тест биремнәрен башкару. Күләме 45 минутка исәпләнгән.

**Максат:** укучыларның ел буена алган белем – күнекмәләрен тикшерү.

**Чыганак:** “Татар әдәбияты” (2кис.). Рус телендә төп белем бирү оешмалары өчен, 7 нче сыйныф. Ә.Р.Мотыйгуллина,Р.Г.Ханнанов, Л.Х.Хисмәтова. – Казан, “Мәгариф-Вакыт”, 2014 ел ; “Татар әдәбияты” Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында (татар телен өйрәнүче укучылар белән) эшләүче укытучылар өчен методик әсбәп, 7нче сыйныф, Ә.Р.Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанов, Г.Г. Мулласалихова, Э.Х.Гыйзәтуллина, Казан, “Мәгариф - Казан” нәшрияты, 2014.

**Предмет нәтиҗәләре:** татар әдипләре исемнәрен һәм алар язган әсәрләрне белү; фольклор төшенчәсенә аңлатма бирә белү; татар әдәбиятына үз мөнәсәбәтен формалаштыра, бәяли белү; укыган әсәр буенча сорауларга җавап бирә алу; әдәбиятның образлы дөньясын сүз сәнгате күренеше буларак аңлау.

**Регулятив нәтиҗәләр:**

- уку хезмәтендә үзенә максат куя, бурычларны билгели белү;

- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белү;
- уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү.

**Танып – белү нәтиҗәләре:**

- - фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерли белү;
- - иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү.

**Еллык контроль тест**

| 1 вариант | 2 вариант |
|---|---|
| **1.Халык йолалары ничә төркемгә бүленә?**<br>А)2<br>Ә)5<br>Б)3<br>**2.Бәби тугач, аны кая алып барганнар?**<br>А)уенчыклар кибетенә<br>Ә)мунчага<br>Б)туганнарына<br>**3.Бәетләрне кем иҗат иткән?**<br>А)язучылар<br>Ә)шагыйрьләр<br>Б)халык<br>**4.Ф.Әмирхан кайда туган?**<br>А)Арча районы Кушлавыч авылында<br>Ә)Казанда<br>Б)Оренбургта<br>**5.Г.Кутуйның “Сагыну” әсәре нинди жанрда язылган?**<br>А)хикәя<br>Ә)повесть<br>Б)нәсер<br>**6.М.Мәһдиевның “Без-кырык беренче ел балалары” повестендә вакыйгалар кайда бара?**<br>А)сугышта<br>Ә)мәктәптә<br>Б)педучилищеда | **1.Бәетләр ничә төркемгә бүленә?**<br>А)3<br>Ә)4<br>Б)5<br>**2.Гаилә йолалары кайсылар?**<br>А)каз өмәсе<br>Ә)туй йоласы<br>Б)Нәүрүз<br>**3.”Алмачуар” әсәрендәге малайның исеме ничек?.**<br>А)Хафиз<br>Ә)Сафа<br>Б)Закир<br>**4.Г.Кутуй “Сагыну” нәсерендә лирик герой кем?**<br>А) сугышчы<br>Ә)ана<br>Б)бала<br>**5.Бөек Ватан сугышында катнашкан язучы:**<br>А)Ф.Әмирхан<br>Ә)С.Хәким<br>Б)Р.Миңнуллин<br>**6.Кырлай авылы белән кайсы кеше бәйле?**<br>А)Сәгъди<br>Ә)Мөхәммәтвәли<br>Б)Зиннәтулла |

| | |
|---|---|
| **7.Һ,Такташ ничәнче елда туган?**<br>А)1901<br>Ә)1902<br>Б)1903<br>**8.”Ак төнбоек” әсәрен кем язган?**<br>А)Роза Хафизова<br>Ә)Рафис Корбан<br>Б)Фәнис Яруллин<br>**9.М.Галиевның “Нигез” әсәре кайсы жанрга керә ?** | **7.Һ.Такташ кайсы авылда туган?**<br>А)Кызылъяр<br>Ә)Сыркыды<br>Б)Иске Кармәт<br>**8.Х.Ибраһимның “Карач” әсәрендәге малайның исеме ничек?**<br>А)Фатих<br>Ә)Айрат<br>Б)Шәяхмәт<br>**9.”Нигез”повестендә әсирлектә булган** |

| | |
|---|---|
| А)роман<br>Ә)хикәя<br>Б)повесть<br>**10.Х.Туфан озак еллар кайда яши?**<br>А)чит илдә<br>Ә)Себердә<br>Б)Мәскәүдә<br>**11.М.Әгъләмов кем ул?**<br>А)скульптор<br>Ә)композитор<br>Б)шагыйрь<br>**12.Берәр язучы яки шагыйрь турында үзегез белгәннәрне языгыз.**<br>***13.Быел яттан өйрәнелгән әсәрне дәфтәрегезгә языгыз** | **геройның исеме:**<br>А)Давыт<br>Ә)Хикмәтулла<br>Б)Байтирәк<br>**10. Гадиләнең этисе Шөһрәткә нәрсә бүләк итә?**<br>А) велосипед<br>Ә)фотоаппарат<br>Б)костюм-чалбар<br>**11.М.Мәһдиев– ул**<br>А)шагыйрь<br>Ә)язучы<br>Б)драматург<br>**12.Берәр язучы яки шагыйрь турында үзегез белгәннәрне языгыз.**<br>***13.Быел яттан өйрәнелгән әсәрне дәфтәрегезгә языгыз** |

8 нче класс

**Укучыларның белем – күнекмәләрен контрольгә алу һәм бәяләү материаллары**
**Чыганак:**

3) Дәреслек: “ Татар әдәбияты” Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен) 8 нче сыйныф. 2 кисәктә. Казан: «Мәгариф-Вакыт»,2015.
4) Өстәмә әдәбият: Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында ( татар телен өйрәнүче укучылар белән) эшләүчеукытучылар өчен методик әсбап. 8 нче с-ф. /Ә.Р. Мотыйгуллина, Р.Г. Ханнанов, Л.К. Хисмәтова, Л.М. Гыйззәтуллина. – Казан: “Мәгариф – Вакыт”нәшр., 2015.

**Контроль эш №1.**

**Үткәрү вакыты: май, 2020 нче ел.**
**Үткәрү формасы:** тест биремнәрен башкару. Күләме 45 минутка исәпләнгән.
**Максат:** укучыларның ел буена алган белем – күнекмәләрен тикшерү.
**предмет нәтиҗәләре:** татар әдипләре исемнәрен һәм алар язган әсәрләрне белү; фольклор төшенчәсенә аңлатма бирә белү; татар әдәбиятына үз мөнәсәбәтен формалаштыра, бәяли белү; укыган әсәр буенча сорауларга җавап бирә алу; әдәбиятның образлы дөньясын сүз сәнгате күренеше буларак аңлау.
**регулятив нәтиҗәләр:**

- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белергә;
- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белергә **өйрәнәчәкләр.**

**танып – белү нәтиҗәләре:**

- логик фикерли белергә;
- иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләргә **өйрәнәчәкләр.**

Биремнәр ел дәвамында үтелгән материалны үз эченә ала. Сораулар “Тарих китабында безнең өчен бик күп хатирәләр саклана”, “Онытылмас еллар”, “Әтинең зур бүреге иртә киелде...” бүлекләреннән алынган.
**Биремнәр**
**1 нче вариант.**
**Планлаштырылган нәтиҗә:** татар әдипләре иҗатына һәм әдәбият теориясенә караган сорауларга дөрес җавап табу.
**База дәрәҗәсе – “Укучы өйрәнәчәк” бүлеге буенча биремнәр:**

1.Риваятьләр ничә төркемгә бүленә?
а) 2 б) 5 в) 3
2. Тарихи риваятьне күрсәтегез:
а) “Сихерче кыз” б) “Хан кызы Алтынчәч” в) “Утсыз кайный торган казан”
3. Татар халык музыкаль уен коралы-
а) баян б) балалайка в) скрипка
4. “Ант” шигыренең авторы кем?
а) б) Фатих Кәрим в) Сибгат Хәким
5. Муса Җәлил кызының исеме ничек?
а) Чулпан б) Әминә в) Рәйханә
6.Клара Булатова-
а) язучы б) шагыйрә в) публицист
7. Разил Вәлиев кайда туа?
а) Азнакай районы б) Түбән Кама районы в) Саба районы
8. “ Буранда” әсәренең авторы кем?
А) Хөсәен б) Мостафа в) Фатыйма
**Югары дәрәҗә - “Укучыга күнекмәләргә ия булу мөмкинлеге бирелә” бүлеге буенча биремнәр:**
9. Т. Миңнуллинның “Моңлы бер җыр” драмасы кемне гәүләндерә?
а) Муса Җәлил б) Габдулла Тукай в) Абдулла Алиш
10 . . “Кыңгараулы яшел гармун” поэмасында төп образ-
а) Әхмәт б) Фатих в) Фазыл

9 нчы класс

**Укучыларның белем – күнекмәләрен контрольгә алу һәм бәяләү материаллары**
**Чыганак:** Өстәмә әдәбият: Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында ( татар телен өйрәнүче укучылар белән) эшләүчеукытучылар өчен методик әсбап. 8 нче с-ф. /Ә.Р. Мотыйгуллина, Р.Г. Ханнанов, Л.К. Хисмәтова, Л.М. Гыйззәтуллина. – Казан: “Мәгариф – Вакыт”нәшр., 2015.
Йомгаклау контроль эше (тест)
**9 нчы сыйныф**
Үткәрү вакыты:__________май 2020 нче ел
**Эшне үткәрү максаты:** укучыларның белемнәрен тикшерү ,бәяләү.
**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**
**Предмет нәтиҗәләре:**
-укучы ел буен алган белемнәрен гамәлдә дөрес-танып белү күнекмәләренә ия булырга тиеш;
**Регулятив УУГ:**
- максатка ирешү юлларын билгеләү;
- кагыйдә, күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу.
**Танып-белү гамәлләре:**
- танып-белү юнәлешендәге максатларны билгеләү;
- укучының үз эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә оештыра белүе, бәяләве, үзенең кызыксынучанлык өлкәсен билгеләве;
- уку мәсьәләсе тирәсендә логик фикерләү
**Тест биремнәре**
**1. Язу һәм язма әдәбият туу һәм үсү өчен нинди шартлар кирәк?**
а) дәүләтчелек, утрак тормыш, шәһәрләр булу, башка илләр һәм халыклар белән төрле бәйләнешләрдә тору;
ә) дәүләтчелек, күчмә тормыш, күчеп йөрү өчен җәйләүләр, башка илләр һәм халыклар белән төрле бәйләнешләрдә тору;

б) аерым – аерым кабиләләр булып яшәү, башка илләр һәм халыклар белән төрле бәйләнешләрдә тору.

**2. Туран (һун) язуы белән язылган нинди истәлекләр сакланган?**

а) кабердашлар;

ә) савыт – саба, алкалар;

б) язма әдәбият.

**3. Рун алфавиты кайсы чорларда гамәлдә йөри?**

а) V – X гасырда;

ә) XII йөзләрдә;

б) VII, VII – XIV йөзләрдә.

**4. Рун язма истәлекләренә нәрсәләр керә?**

а) язма әдәбият;

ә) савыт – саба, алкалар;

б) эпитафик, ягъни кабердаш язмалары;

**5. "Диване лөгатет төрек" ("Төрки телләр сүзлеге") җыентыгының авторы кем?**

а) Йосыф Баласагунлы;

ә) Мәхмүт Кашгарый;

б) Әхмәт Йүгнәки;

**6. Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" дастаны кайсы чорга карый?**

а) Алтын Урда чоры;

ә) Иң борынгы язма әдәби мирас;

б) Болгар чоры;

**7. "Кыйссаи Йосыф"ның төп өлеше ничә фасылдан тора?**

а) 15;

ә) 8;

б) 18;

**8. Йосыфтагы хәлиткеч сыйфатлар?**

а) укымышлылык;

ә) сабырлык, тугрылык;

б) шәфкатьлелек;

**9. Кол Галинең фикеренчә бәхетле тормышның нигезе –**

а) бердәмлектә, татулыкта, кешелекле мөнәсәбәтләрдә;

ә) Йосыф кебек һәрьяктан камил затларда;

б) матурлыкта, көчтә, алдан күрүчәнлектә;

**10. "Хөсрәү вә Ширин"ның авторы?**

а) Хәрәзми;

ә) Котб;

б) Сәйф Сараи;

**11. Рәдиф нәрсә ул?**

а) шигырь төзелеше;

ә) Сәйф Сараи әсәренең исеме;

б) газәлдә кабатланып килүче аерым сүз яки сүзләр төркеме;

**12. Сәйф Сараи кайда туган?**

а) Казан шәһәрендә;

ә) Камышлы шәһәрендә;

б) Сарай шәһәрендә;

**13. Сәйф Сараиның әсәрләре?**

а) "Идегәй"; "Кодатгу белек";

ә) "Гөлстан бит-төрки", "Сөһәйл вә Гөлдерсен";

б) "Хөсрәү вә Ширин", "Күңел";

**14. Газәл жанрына хас сыйфатлар?**

а) тартмалы композиция;

ә) башта 3 юлы үзара рифмалашкан, дүртенче юлы рифмасыз дүртьюллыклар, һәр строфа имди сүзенә тәгәлләнә;
б) икеьюллык строфалардан – бәетләрдән төзелә, рифмалардан соң рәдиф кабатланып килә, уртача күләме 5 - 12 строфадан тора, ахырында автор үзенең исемен яки кушаматын куллана.

**15.** ***“Кыз әйләнде бу батыр яшь тирәли,***
***Җир әйләнгән төсле кояш тирәли.”*** Бу өзекләр кайсы әсәрдән алынган?
а) “Хөсрәү вә Ширин”,
ә) “Сөһәйл вә Гөлдерсен”;
б) “Идегәй”;

**16. “Идегәй”нең жанры?**
а) поэма;
ә) дастан;
б) әкият;

**17. “И Идел йорт, Идел – йорт**
**Идел эче имин йорт,**
**Атам кияү булган йорт,**
**Иелеп хөрмәт кылган йорт;**
**Анам килен булган йорт,**
**Иелеп сәлам биргән йорт; ...”** Бу юллар кайсы әсәрдән алынган?
а) “Кодатгу белек”;
ә) “Сөһәйл вә Гөлдерсен”;
б) “Идегәй”;

**18. Идегәйнең чын исеме?**
а) Идегәй;
ә) Котлыкыя;
б)Туктамыш;
в) Кобыгыл;

**19. Дастанга хас сыйфатлар?**
а) икеьюллык строфалардан – бәетләрдән төзелә, рифмалардан соң рәдиф кабатланып килә, уртача күләме 5 - 12 строфадан тора, ахырында автор үзенең исемен яки кушаматын куллана.
ә) башта 3 юлы үзара рифмалашкан, дүртенче юлы рифмасыз дүртьюллыклар, һәр строфа имди сүзенә тәгәлләнә;
б) лиро-эпик характердагы әдәби әсәр. Анда вакыйга-хәлләр уй-кичерешләр белән үрелеп бара. Кагыйдә буларак әкияти сюжетлар, легенда-риваятьләр эшкәртелә, хыялый һәм чынбарлык күренешләре үзара үрелеп бара.